**Кукмара муниципаль районы Өркеш**
**Авыл җирлеге башкарма комитеты**

# КАРАР

**«30» гыйнвар 2024 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2024 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 23 гыйнварындагы 46 номерлы карары, «Татарстан Республикасында «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авылы башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2024 елның 1 февраленнән гамәлгә кертү һәм № 1 Кушымта һәм № 2 Кушымта нигезендә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең 2023 елның 31 гыйнварындагы 14 номерлы карарын 2024 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлегекарарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулайук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче: А.Ш. Әгъләмова

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 30 гыйнварындагы 3 номерлы карарына 1 нче кушымта

**2023 елның 01 февраленнән Татарстан РеспубликасыКукмарамуниципаль районы Өркеш авыл җирлегендә җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең хакы**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү хакы (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3574,40 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү | 1150,3 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3645,5 |
| **Барлыгы** | **8370,20** |

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 30 гыйнварындагы 3 номерлы карарына 2 нче кушымта

**2023 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегендә җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең хакы**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү хакы (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү (киендерү) | 150,48 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3423,92 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү | 1150,3 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3645,5 |
| **Барлыгы** | **8370,20** |